Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

# Сюжетлы - рольле уеннар

Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификацион категорияле
татар теле тәрбиячесе

## Кереш

Балаларны туган телдә, татар телендә дөрес һәм матур сөйләшергә өйрәтүдә, аларда сәнгатьле сөйләм күнекмәсе булдыруда сюжетлы-рольле уеннар аеруча нәтиҗәле. Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү өчен төзелгән “Татарча сөйләшәбез” программасында  сюжетлы-рольле уеннар актив кулланыла торган ысул булып торалар.

Чит телне өйрәнгән вакытта, уен кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Уенны, төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату, ныгыту вакытында уңай технология буларак файдаланырга була. Сюжетлы-рольле уеннар барышында балалар үзләрен иркен һәм тигез дәрәҗәдә хис итәргә, тәрбияченең басымын һәм буйсынырга тиешле кеше икәнен сизеп түгел, ә кызыклы итеп уйнаучы уенчы буларак кабул итәргә тиешләр. Шуңа күрә балачакның һәрбер этабында уенны шундый итеп төзергә кирәк ки, бала үзенә уенның яңа һәм катлаулырак якларын ача алсын. Уенның сюжетын аңлау – аның уңышлы барышын тәэмин итә; партнерның нәрсә эшләгәнен аңлау – аның белән аралашуда төп шарт булып тора. Уен вакытында баланың акыл үсешендә генә түгел, ә шәхес буларак формалашуында да алга китеш күренә. Уендагы төрле рольләргә кереп, бала реаль тормыштагы кешеләрнең эш-гамәлләрен кабатлый, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, эмоцияләрне һәм кичерешләрне уенга күчерә.

Балаларның сөйләмен активлаштыру максатыннан чыгып, һәр шөгыльгә нинди дә булса сюжетлы-рольле уен кертелә.  Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше.

# Әнигә булышам



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру; диалогик сөйләмне үстерү; аралашу теләге тудыру, хезмәт сөючәнлек тәрбияләү.
**Җиһазлау:** Өстәл, кәрзин, кишер, таз, әни, кыз битлеге.
**Катнашалар:** ике бала (әни, кыз)
**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Искәрмә:** Ю сүзе шушы шигъри юллар аша искә төшерелә.
Чисто мыться я люблю
Мой! А будет
Просто “ ю.

**Уен барышы:**

**В: Воспитатель приглашает Катю и Киру.**
-Катя, кил монда. Кира, кил монда. Катя син әни, Кира син кыз. (Кира кыз, Катя әни битлеген кия)
-Катя син әни?
-Әйе, мин әни. (Тәрбияче Катяга яшелчәләр салынган кәрзин бирә.)
-Катя, мә кәрзин.
-Кира син малай?
-Юк, мин кыз. (Кира үз урынына барып утыра. Тәрбияче өстәлгә таз куя.)
**В: Мама купила овощи. Овощи грязные. Позвала свою дочь Киру и велела помыть овощи.**
-Катя кил монда. Катя, мә кишер. Кишер пычрак. Кишер ю. ( Катя демонстрирует, как моет морковь.)
**В: Мама увидела, как ее дочь старается и похвалила.**
- Кира зур кыз. Кира кишер юа.
-Әйе, мин зур кыз. Мин кишер юам. Кишер чиста.
-Әни мә кишер. Кишер чиста.
-Рәхмәт.

# Кафеда



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү күнекмәләрен үстерү. Аралашу теләге тудыру.

**Җиһазлау: Өстәл, чынаяк, кашык, тәлинкә.**
**Катнашалар:** официант, ике бала (малай,кыз).
**Искәрмә:** "Нишлисең?" соравы мәктәпкә әзерлек төркемендә кулланыла.
**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Уен барышы:**

**В: Катя и Саша зашли в кафе. Они пригласили официанта. Катя заказала чай, а Саша заказал салат**.
-Официант , кил монда.
-Нәрсә кирәк?
-Миңа чәй бир әле.
-Миңа салат бир әле.
-Мә,чәй. Чәй тәмле, баллы. Чәй эч.
-Рәхмәт
-Мә, салат. Салат тәмле. Салат аша
-Рәхмәт.
**В: Саша заметил, что у него нет ложки. Пригласил официанта. Попросил ложку.**
-Официант, кил монда. Кашык юк. Кашык бир әле.
-Мә кашык. Кашык чиста.
-Рәхмәт.
**В: Катя и Саша завели разговор и спросили друг у друга: "Нишлисең?"**
-Катя нишлисең?
-Мин чәй эчәм. Чәй тәмле. Саша нишлисең?
-Мин салат ашыйм. Салат тәмле.
**В: Они пригласили официанта, сказали спасибо и попращались.**
-Рәхмәт!
-Сау булыгыз!
-Сау булыгыз!

# Кибеттә



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру; диалогик сөйләмне үстерү; аралашу теләге тудыру.

**Җиһазлау:** Төрле зурлыктагы, төстәге кием-салым рәсемнәре, ике кием-салым кибете.

**Катнашалар:** сатучы, ике бала (малай, кыз).

**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Уен барышы:**

**В: Настя и Кирилл пришли в магазин одежды.**

-Исәнмесез!

-Исәнмесез!

-Нәрсә кирәк?

-Миңа күлмәк кирәк.

-Нинди күлмәк?

-Кызыл, кечкенә күлмәк.

-Ничә күлмәк?

-Бер күлмәк.

-Мә, кызыл, кечкенә күлмәк. Рәхмәт

**В: Настя показала платье Кириллу. Но платье Кириллу не понравилось. Он сказал: « Нет. Платье маленькое». Настя обратно отдала платье.**

-Юк, күлмәк кечкенә.

-Күлмәк кечкенә. Мә күлмәк. Рәхмәт. Сау булыгыз.

-Сау булыгыз.

**В: Кирилл в другом отделе нашел красивое, желтое платье и пригласил Настю.**

-Настя кил монда. Күлмәк матур, зур, сары.

-Сары, зур күлмәк бир әле.

-Ничә күлмәк?

-Бер күлмәк.

-Мә сары, зур күлмәк.

-Рәхмәт! Сау булыгыз!

-Сау булыгыз!

# Автобуста



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру; диалогик сөйләмне үстерү; аралашу теләге тудыру, өлкәннәргә карата игътибарлылык тәрбияләү.
**Җиһазлау:** Автобус макеты, урындыклар, светофор, билетлар, руль, бабай битлеге.
**Катнашалар:** шофер, бабай, пассажирлар.
**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Уен барышы:**

**В:Дети сели в автобус. Поехали в музей. Марьяна купила у водителя четыре билета.**
-Миңа билет бир әле?
-Ничә билет?
-Дүрт билет.
-Бер, ике, өч, дүрт. Мә, дүрт билет.
-Рәхмәт.
**В:Полина купила у водителя два билета.**
-Миңа билет бир әле?
-Ничә билет?
-Ике билет.
-Бер, ике. Мә, ике билет.
-Рәхмәт.
**В:Настя купила у водителя два билета.**
-Миңа билет бир әле?
-Ничә билет?
-Ике билет.
-Бер, ике. Мә, ике билет.
-Рәхмәт.
**В: Дети завели разговор. Дети, сидящие в первом ряду, поздоровались друг с другом.**
-Исәнме, Полина!
-Исәнме, Рома!
**В: Дети, сидящие во втором ряду, узнали друг у друга как дела и пожелали друг другу "Доброго дня!" – "Хәерле көн!"**
-Хәлләр ничек, Саша?
-Әйбәт, рәхмәт.
-Хәлләр ничек, Даниил?
Әйбәт, рәхмәт.
- Хәерле көн, Саша!

-Рәхмәт, Даниил.
- Хәерле көн, Даниил!
-Рәхмәт, Саша.
**В: Дети, сидящие в третьем ряду, не были знакомы, они решили познакомиться.**
-Исәнмесез!
-Исәнмесез!
-Син кем?
- Мин малай. Мин Фадей.
-Син кем?
-Мин Настя. Мин зур, матур, әйбәт кыз.
**В: Дети, сидящие в четвертом ряду, делали друг другу комплимент.**
-Катя син матур, зур кыз!
-Рәхмәт, Тимур! Тимур син әйбәт малай.
-Рәхмәт, Катя!
**В: На пути светофор.**
-Нинди?
-Кызыл.
-Барабызмы?
-Юк.
Нинди?
-Сары.
-Барабызмы?
-Юк.
-Нинди?
-Яшел.
-Барабызмы?
-Әйе.
**В: Поехали дальше. На пути остановка. Зашел дедушка. Рома уступил ему место.**
-Бабай, кил монда. Утыр.
-Рәхмәт.
**В: Поехали дальше. Ребята решили спеть песню “Мин барам”. Воспитатель показыает рисунки. (Музей, кино, кибет).**
-Мин барам, барам.
Музейга барам, барам.
**В: Последняя остановка. Все вышли из автобуса.**

# Туган көн



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру; диалогик сөйләмне үстерү; аралашу теләге тудыру, бер-береңә игътибарлылык, хөрмәт тәрбияләү.
**Җиһазлау:** Өстәл, урындыклар, машина, туп, чынаяклар.
**Катнашалар:** Малай һәм кунаклар.
**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Уен барышы:**

**В: Сегодня день рождения Тимура. Рустам и Богдан пришли поздравить Тимура. Стук в дверь. Тимур встречает гостей.**
-Кем анда?
-Мин Рөстәм. Мин Богдан.
-Исәнме,Тимур!
-Исәнмесез!
- Хәлләр ничек, Тимур?
-Әйбәт, рәхмәт.
-Хәлләр ничек, Богдан?
-Әйбәт, рәхмәт.
-Хәлләр ничек, Рөстәм?
-Әйбәт, рәхмәт.
**В:Мальчики дарят подарки Тимуру.**
-Тимур, мә кызыл туп.
-Рәхмәт. Туп матур, кызыл.
-Тимур, мә зур, матур машина.
-Рәхмәт. Машина матур. Машина зур.
**В:Тимур позвал их и предложил им сесть.**
-Рөстәм, Богдан кил монда.
-Рөстәм утыр.
-Рәхмәт.
-Богдан утыр.
-Рәхмәт.
**В:Тимур угощает их вкусным соком.**
-Богдан, мә сок. Сок тәмле. Сок эч.
-Рәхмәт.
Рөстәм, мә сок. Сок тәмле. Сок эч.
-Рәхмәт.
- Сок тәмле.
-Сок баллы.
**В:Дети попращались друг с другом.**

-Сау бул,Тимур. Рәхмәт Тимур.
-Сау булыгыз. Рәхмәт.

# Без музейда



**Бурычлар:** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Аралашу теләге тудыру. Бер-береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.
**Җиһазлау:** яшелчә, җиләк-җимеш муляжлары.
**Катнашалар:** Балалар һәм экскурсовод.
**Зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.**

**Уен барышы:**

**В:Ребята, мы с вами находимся в ботаническом музее. Давайте подойдем к экскурсоводу и поздороваемся.**
-Исәнмесез!
-Исәнмесез!
**В:Экскурсовод начал свой рассказ.**
-Бу алма. Тәмле, кызыл алма. Бу кыяр. Бу яшел кыяр.Зур кыяр. Бу кечкенә кыяр. Бу помидор. Помидор зур, кызыл, тәмле. Бу кишер. Кишер тәмле, зур. Бу кечкенә кишер. Бу лимон. Лимон сары.
**В:У ребят появился ряд вопросов к экскурсоводу. Алена и Катя, показывая на помидор, спросили: “Это яблоко?”**
-Буалма?
-Юк, бу помидор. Помидор тәмле, кызыл.
-Рәхмәт.
**В:Владик и Кира, показывая на большой огурец, спросили: “Это большой огурец?”**
-Әйе, бу зур кыяр. Бу кечкенә кыяр.
**В:Ксюша и Ника стояли около моркови и говорили про морковь.**
-Бу кишер.
-Зур кишер.
-Кечкенә кишер. Кишер тәмле, баллы.
**В:Катя и Алена решили купить на память сувениры и подошли к продавцу.**
-Миңа алма бир әле.
- Ничә алма?
-Бер алма
-Нинди алма?
-Кызыл алма.
-Мә, бер,кызыл алма.
-Рәхмәт.
**В:Экскурсовод организовал с детьми игру “Бу нәрсә?”.**

-Алма, алма
Тәмле алма,
Зур алма,
Кызыл алма.
**В:Ребята сказали спасибо и попращались.**
-Сау булыгыз! Рәхмәт!
-Саубулыгыз!

